ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендә «органнары» сүзеннән соң «озайтылган көн төркемнәре эшчәнлеген,» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
«3. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы, федераль башкарма хакимиятнең гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм аны гамәлгә ашыру, норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда педагог хезмәткәрләр әзерли торган документларның әлеге федераль орган тарафыннан раслана торган исемлегенә өстәп, мондый документларның өстәмә исемлеген расларга хокуклы.»;

3) 12 статьяда «халыкка күрсәтелә торган белем бирү хезмәтләренең һәркем алырлык булуын һәм» сүзләрен «белемне һәркем алырлык булуын һәм аның» сүзләренә алмаштырырга;

4) 18 статьяда:

а) исемендә «Мәгариф өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне» сүзләрен «Уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясендә уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә һәм Федераль законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 өлештә «мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар» сүзләрен «уку-укыту программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләме» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлештә «Мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарга» сүзләрен «Уку-укыту программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә» сүзләренә алмаштырырга;

д) 4 өлештә «мәгариф өлкәсендә дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнар шул исәптән белем алучыларның санына бәйле булмаган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны да күздә тотарга тиеш» сүзләрен «уку-укыту программасын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү күләменә шул исәптән белем алучыларның санына бәйле булмаган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнар да керергә тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

е) 5 өлештә «мәгариф өлкәсендә тиешле дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпкә алып» сүзләрен «дәүләт йөкләмәсен яисә муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тәртипкә охшаган тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты  Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 04 октябрь
№ 62-ТРЗ